**IV ЧАКЫРЫЛЫШ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТОЙГЕЛДЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ XXII УТЫРЫШЫ**

**К А Р А Р № 43**

Тойгелде авылы 28 сентябрь 2022 ел

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Тойгелде авыл җирлеге Советының 09.09.2017 елның 2 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында «Мөслим муниципаль районы Тойгелде авыл җирлегенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру тәртибен раслау һәм массакүләм мәгълүмат чараларына Мөслим муниципаль районы авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны һәм Башкарма комитетның контракт буенча җитәкчесе вазыйфасын биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакында»**

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының «Дәүләт Вазыйфаларын биләүче затлар һәм аларның керемнәренә башка затлар чыгымнарының туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законга туры китерү максатларында КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Тойгелде авыл җирлеге Советының 09.09.2017 елдагы 2 нче номерлы карарына «Мөслим муниципаль районы Тойгелде авыл җирлегенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру тәртибен раслау һәм массакүләм мәгълүмат чараларына Мөслим муниципаль районының Тойгелде авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны һәм Башкарма комитетның контракт буенча җитәкчесе вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү тәртибен раслау турында» түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 3 пунктның «г» пунктчасын түбәндәгечә бирергә:

«г) җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләре, пайлар), цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта сатып алу чыганаклары турында белешмәләр, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы (мондый алыш-бирешнең суммасы) хисап чорына кадәрге соңгы өч елда затның һәм аның хатынының (иренең) гомуми кеременнән артып китсә.»;

1.2. 6 пунктны түбәндәгечә бәян итәргә:

«6. Әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән белешмәләрне рәсми сайтка урнаштыру Мөслим муниципаль районының Тойгелде авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары тарафыннан тәэмин ителә.»;

1.3. 7 пунктның «а» пунктчасын төшереп калдырырга.

2. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Тойгелде авыл җирлеге Советының 26.07.2022 39 нчы номерлы «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Тойгелде авыл җирлеге Советының 09.09.2017 елның 2 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» «Мөслим муниципаль районы Тойгелде авыл җирлегенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру тәртибен раслау һәм массакүләм мәгълүмат чараларына Мөслим муниципаль районының Тойгелде авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны һәм Башкарма комитетның контракт буенча җитәкчесе вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү тәртибен раслау турында» карарын бетерергә.

3. Әлеге карарны Тойгелде авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Авыл җирлеге башлыгы Минһаҗев Д.М.